ИПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
КАЧЕЛИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ул.Центральная, д. 200, с.Качелино ,
Арский муниципальный район, 422013

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
КӘЧЕ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
Үзәк урам, 200 йорт, Кәче авылы,
Арча муниципаль районы, 422013

Тел. (84366)52-3-93, факс (84366)52-3-93 E-mail: Kach.Ars@tatar.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

«02» июнь 2025 ел. № 36

Татарстан Республикасы Арча муницпаль районы Кәче авыл җирлегә башкарма комитетының “Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының “Кәче авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге территориясендә төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контроль кысаларында 2025 елга закон белән саклана торган кыйммәтләргә зыян (зарар) китерү куркынычларын кисәтү программасын раслау турында” 2024 елның 09 декабрендәге 21 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

“Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында” 2020 елның 31 июлендәге 248-ФЗ номерлы Федераль законның 44 статьясы, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең “Контроль (күзәтчелек) органнары тарафыннан закон белән саклана торган кыйммәтләргә зыян китерү (зарар китерү) куркынычларын кисәтү программасын эшләү һәм раслау кагыйдәләрен раслау турында” 2021 елның 25 июнендәге 990 номерлы карары нигезендә Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының Кәче авыл җирлеге Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының Кәче авыл җирлеге башкарма комитетының “Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының “Кәче авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге территориясендә төзеклəндерү өлкәсендә муниципаль контроль кысаларында 2025 елга закон белән саклана торган кыйммәтләргә зыян (зарар) китерү куркынычларын кисәтү программасын раслау турында” 2024 елның 09 декабрендәге 21 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

- 3 бүлек. Кисәтү чаралары исемлегенә, аларны үткәрү срокларына (ешлыгына) әлеге карарга кушымта нигезендә 3, 4 пунктлар өстәргә.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында(http://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Арча муниципаль районының рәсми сайтында (http://arsk.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үземдә калдырам.

Кәче авыл
җирлеге башлыгы Р.Р.Гәрәев

ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ КАЧЕЛИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ИНН 1609009844

*Кәче авыл җирлеге башкарма комитетының 2025 елның 02 июнендәге 36 номерлы карарына Кушымта*

Раздел 3 Кисәтү чаралары исемлеге, аларны үткәрү сроклары (ешлыгы)

| № | Чара исеме | Үткәрү вакыты | Җаваплы башкаручы |
|---|---|---|---|
| 4 | Мәҗбүри профилактик визит.<br>Мәҗбүри профилактик визит контрольдә тотылучы затның аны үткәрүдән баш тартуын күздә тотмый.<br>Мәҗбүри профилактик визит кысаларында инспектор кирәк булганда тикшерү, кирәкле документларны сорап алу, пробалар (үрнәкләр) алу, инструменталь тикшерү, сынау, экспертиза үткәрә.<br>Мәҗбүри профилактик визит уздыру срогы ун эш көненнән артмаска тиеш һәм экспертиза, сынаулар уздыру өчен кирәкле срокка озайтылырга мөмкин. | Мәҗбүри профилактик визитлар уздыру "Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында" 2020 елның 31 июлендәге 248-ФЗ номерлы (2024 елның 28 декабрендәге редакциясендә Федераль закон белән билгеләнә. | Кәче авыл җирлеге башлыгы |
| 5 | Контрольдә тотылучы зат инициативасы буенча профилактик визит.<br>Контрольдә тотылучы зат инициативасы буенча профилактик визит аның гаризасы буенча үткәрелергә мөмкин, әгәр мондый зат кече эшмәкәрлек субъектларына карый, социаль юнәлешле коммерцияле булмаган оешма йә дәүләт яки муниципаль учреждение булса.<br>Тикшереп торылучы зат профилактик визит уздыру турында гаризаны (әлеге статьяда алга таба - гариза) бердәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы яисә дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең региональ порталы аша бирә. Контроль (күзәтчелек) органы гаризаны ун эш көне эчендә карый һәм профилактик визит үткәрү турында йә аны үткәрүдән баш тарту турында карар кабул итә, бу хакта контрольдә тотылучы затка хәбәр итә. | Контрольдә тотылучы зат гаризасы буенча | Кәче авыл җирлеге башлыгы |